КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 апрель г.Казань № 257

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче, 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче, 2019 ел, 29 июль, 629 нчы, 2020 ел, 25 август, 737 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кеушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 19 апрель, 257 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге

| Т/с | Күрсәткеч атамасы, үлчәү берәмлеге | Күрсәткечне исәпләү өчен җаваплы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары | Монито-рингның вакытлы-лыгы | Күрсәткечнең мәгънәсен исәпләү |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Җирле бюджетның салым керемнәренең планлы күрсәткечләрен үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - җирле бюджетның салым керемнәренең фактик күләме, сум; B - җирле бюджетның салым керемнәренең планлы күрсәткечләре күләме, сум |
| 2. | Җирле бюджетның салым булмаган керемнәренең планлы күрсәткечләрен үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - җирле бюджетның салым булмаган керемнәренең фактик күләме, сум; B – җирле бюджетның салым булмаган керемнәренең планлы күрсәткечләре күләме, процентлар |
| 3. | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына акчалар күчерү буенча | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - Татарстан Республикасы Президенты |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү, процентлар | | | каршындагы Дәүләт торак фондына күчерелгән акчаларның факттагы күләме, сум;<br>В - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына акчалар күчерү буенча кабул ителгән йөкләмәләр күләме, сум |
| 4. | Эре һәм урта предприятиеләрнең төп капиталына (бюджет акчаларыннан тыш) инвестицияләр күләме буенча планлы күрсәткечләрне үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - эре һәм урта предприятиеләрнең төп капиталына инвестицияләрнең факттагы күләме (бюджет акчаларыннан тыш), мең сум;<br>В - эре һәм урта предприятиеләрнең төп капиталына инвестицияләрнең планлы күләме (бюджет акчаларыннан тыш), мең сум |
| 5. | План күрсәткечләренә карата торакны гамәлгә кертү, процентлар | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - гамәлгә кертелгән торакның факттагы күләме, кв.метр;<br>В - агымдагы елда торакны гамәлгә кертү буенча планлы күрсәткечләр, кв.метр |
| 6. | Эшләр башкару графиклары нигезендә башкарыла торган иҗтимагый инфраструктура объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау программалары өлеше, процентлар | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - эшләр башкару графиклары нигезендә башкарыла торган иҗтимагый инфраструктураны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау программалары саны, берәмлекләр; |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | В - муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә башкарыла торган иҗтимагый инфраструктураны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау программаларының гомуми саны, берәмлекләр |
| 7. | Муниципаль юл эшләре программасы нигезендә юл эшләре планын үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: А - муниципаль юл эшләре программасы нигезендә юл эшләре планының фактта башкарылган күләме, сум; В - муниципаль юл эшләре программасы нигезендә юл эшләре планы буенча эшләрнең гомуми күләме, сум |
| 8. | Билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары (алга таба - ҖҮО) акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган халыкны профилактик медицина тикшерүе һәм диспансеризацияләү белән тәэмин итү, процентлар | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: А - билгеләнгән тәртиптә, диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләре барышында, хисап чорына ҖҮО чаралары исәбеннән тикшерелә торган затлар саны, абсолют берәмлекләр; В - билгеләнгән тәртиптә, диспансеризация барышында һәм хисап чорында ҖҮО чаралары исәбеннән башкарыла торган профилактик медицина тикшерүләре санының планлы мәгънәсе, абсолют берәмлекләр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Халыкның үлүе 1 000 кешегә | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | квартал саен | статистик мәгълүматлар |
| 10. | Авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм крестьян-фермер хуҗалыкларында авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем күләме, узган елга карата процентларда | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | квартал саен | статистик мәгълүматлар |
| 11. | Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында басылып чыккан мөрәҗәгатьләр өлеше, аларга «Гариза хәл ителгән» статусы бирелгән, процентлар | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - хисап чорына Татарстан Республикасының «Халык контроле»* дәүләт мәгълүмат системасында басылып чыккан мөрәҗәгатьләр саны, аларга «Гариза хәл ителгән»** статусы бирелгән (үсә баручы нәтиҗә белән), берәмлек; B - хисап чорына Татарстан Республикасының «Халык контроле»* дәүләт мәгълүмат системасында басылып чыккан мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны** (үсә баручы нәтиҗә белән), берәмлек |
| 12. | Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләренең билгеләнгән контроль срокларында муниципаль район (шәһәр округы) башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарылган эшләр өлеше, күрсәтелгән затлар тарафыннан үтәү срогы билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында йөкләмә- | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияләү идарәсенең контроль бүлеге | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләренең билгеләнгән контроль срокларда үтәлгән саны, алар өчен күрсәтелгән затлар тарафыннан әлеге |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | ләрнең гомуми күләмендә, процентлар | | | вәкаләтләр кысаларында үтәү срогы билгеләнгән, берәмлекләр;<br>В - Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләренең билгеләнгән контроль срокларында билгеләнгән күрсәткечләрнең гомуми саны, алар өчен күрсәтелгән затлар тарафыннан бирелгән вәкаләтләр кысаларында үтәү срогы билгеләнгән, берәмлекләр |
| 13. | Рәсми булмаган эш белән тәэмин ителешне киметү буенча кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>А - төзелгән хезмәт шартнамәләренең факттагы саны, берәмлекләр;<br>В - планлаштырыла торган елга төзелергә тиешле хезмәт шартнамәләре саны, берәмлекләр |
| 14. | Россия Федерациясе Президентының «Шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Президентының «Шәһәр округларының һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2008 елның 28 апрелендәге 607 | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>А - башкарылган күрсәткечләр саны, берәмлекләр;<br>В - күрсәткечләрнең гомуми саны, берәмлекләр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 елның 17 декабрендәге 1317 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Президентының«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 2 пунктындагы «и» пунктчасы күрсәткечләрен үтәү, процентлар | | | |
| 15. | Хезмәткә сәләтле яшьтәге инвалидларның гомуми санында эшләүче хезмәт яшендәге инвалидлар саны, процентлар | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - муниципаль районда (шәһәр округында) эшли торган хезмәт яшендәге инвалидлар саны, кеше;<br>В - муниципаль районда (шәһәр округында) яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтәге инвалидларның гомуми саны, кеше |
| 16. | Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылган норматив хокукый актлар өлеше, процентлар | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - хисап чорында Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырылган муниципаль норматив хокукый актлар саны, берәмлекләр;<br>В - хисап чорында бастырылган муниципаль норматив хокукый актларның гомуми саны, берәмлекләр |
| 17. | Үз-үзләрен эш белән тәэмин итүчеләрне, шәхси эшмәкәрләрне да кертеп, (үсә баручы нәтиҗә белән) теркәүне исәпкә алып, кече һәм урта эшмәкәрлек | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләрнең, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | өлкәсендә эшләүчеләр санының план күрсәткечләрен үтәү, процентлар | | | үзмәшгульләрне исәпкә алып, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, фактагы саны, кеше;<br>В - үзмәшгульләрне теркәүне исәпкә алып, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләрнең планлы саны, кеше |
| 17.1. | шул исәптән үзмәшгульләр саны буенча план күрсәткечләрен үтәү, процентлар | | | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - теркәлгән үзмәшгульләрнең фактагы саны, кеше;<br>В - теркәлгән үзмәшгульләрнең планлы саны, кеше |
| 18. | Ярлылык дәрәҗәсенең кыскаруы, процентлар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | статистик мәгълүматлар |
| 19. | Хисап чорында sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып милеккә сатылган яисә арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өлеше, процентлар | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>А - хисап чорында Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) милкенә сатылган яисә sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштыру юлы белән арендага бирелгән мөлкәт объектлары саны, берәмлекләр;<br>В - хисап чорында Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) милкендәге яисә арендага бирелгән мөлкәт объектларының гомуми саны, берәмлекләр.<br>Хисап чоры - агымдагы елның кварталы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (тиешенчә 1 гыйнвардан 31 мартка кадәр - 1 апрельдән 30 июньгә кадәр, 1 июльдән 30 сентябрьгә кадәр, 1 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр). Хисап чорының соңгы көне ял көненә туры килсә, хисап чоры азагында хисап кварталының соңгы аеның соңгы эш көне кабул ителә |
| 20. | Җир участокларын бушлай алган күпбалалы гаиләләр өлеше, гомумән алганда, җир кишәрлекләрен түләүсез бирү өчен учетка баскан күпбалалы гаиләләр өлеше хисап елы башына, процентлар | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>A - җир кишәрлекләре түләүсез алган күпбалалы гаиләләр саны, хисап датасына, гаиләләр саны;<br>B - җир кишәрлеген түләүсез бирү өчен учетка баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми саны, хисап елы башына, гаиләләр саны.<br>Хисап датасы - хисап кварталының соңгы аеның соңгы числосы (тиешенчә 31 март, 30 июнь, 30 сентябрь, 31 декабрь). Әгәр билгеләнгән хисап датасы ял көненә туры килсә, хисап датасына хисап кварталының соңгы аеның соңгы эш көне кабул ителә |
| 21. | Муниципаль милек хокукы дип танылган файдаланылмаган җир өлешләренең мәйданы өлеше, процентлар | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$,<br>монда:<br>A - муниципаль милекне тану турында суд карары булган файдаланылмаган җир өлешләре мәйданы, гектар; |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | B - Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә файдаланылмаган җир өлешләренең гомуми мәйданы, гектар.<br>Хисап датасы - хисап кварталының соңгы аеның соңгы числосы (тиешенчә 31 март, 30 июнь, 30 сентябрь, 31 декабрь). Әгәр билгеләнгән хисап датасы ял көненә туры килсә, хисап датасына хисап кварталының соңгы аеның соңгы эш көне кабул ителә |
| 22. | Мәдәни чараларга килүчеләр саны буенча план үтәлеше, процентлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>A - мәдәни чараларга килүчеләрнең фактик саны, берәмлекләр;<br>B - мәдәни чараларга баруның планлы саны, берәмлекләр |
| 23. | Уртача айлык реаль хезмәт хакы дәрәҗәсенең план күрсәткечләрен үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>A - уртача айлык реаль хезмәт хакы дәрәҗәсенең факттагы мәгънәсе;<br>B - уртача айлык реаль хезмәт хакы дәрәҗәсенең планлы әһәмияте |
| 24. | Халыкның реаль җан башына акчалата кереме дәрәҗәсенең планлы күрсәткечләрен үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>A - халыкның җан башына туры килә торган акчалата кеременең чын мәгънәсендә әһәмияте;<br>B - халыкның реаль җан башына акчалата кереме дәрәҗәсенең планлы әһәмияте |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 25. | Атмосфера һавасына стационар чыганаклар тарафыннан зарарлы матдәләрне чыгару планын үтәү, процентлар | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | ел саен | статистик мәгълүматлар |
| 26. | Мәгариф оешмалары, коммерциячел булмаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базасында ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм итү үзәкләре (берләшмәләре, берлекләре) тарафыннан җәлеп ителгән Татарстан Республикасы гражданнары саны буенча план, процентлар | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | квартал саен | $V = \frac{A}{B} \times 100$, монда: A - мәгариф оешмалары, коммерциячел булмаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базасында ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм итү үзәкләре (берләшмәләре, берлекләре) тарафыннан җәлеп ителгән Татарстан Республикасы гражданнарының факттагы саны, мең кеше; B - мәгариф оешмалары, коммерциячел булмаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр базасында ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм итү үзәкләре (берләшмәләре, берлекләре) тарафыннан җәлеп ителгән Татарстан Республикасы гражданнары план саны, мең кеше |
| 27. | Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм төрле чараларда катнашкан оешмаларда белем алучы җиде яшьтән 30 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, шул исәптән конкурс, шулай ук белем бирү вакыйгалары, процентлар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B}$, монда: A - белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм төрле чараларда катнашкан оешмаларда белем алучы җиде яшьтән 30 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, шул исәптән конкурс, шулай ук агымдагы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | елда белем бирү вакыйгалары<br>В - белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм төрле чараларда катнашкан оешмаларда белем алучы җиде яшьтән 30 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, шул исәптән конкурс, шулай ук агымдагы елда белем бирү вакыйгалары |

*Билгеләнгән хәбәрнамәләр - ел башыннан билгеләнгән чорда эшкәртелә торган мөрәҗәгатьләр саны (үсә баручы нәтиҗә белән).

**Хәбәрнамәләр саны - "Эштә", "Планлаштырылган", "Хәл ителгән", "Мотивлаштырылган кире кагу" колонкаларында мөрәҗәгатьләр суммасы.